

2025 елнын 9 июньнән 22 июньгә кадәр Мордовия Республикасы Коч-курово районы «Орбита» балалар сәламәтләндерv лагеры базасында «Яшә, туган тел!» жәйге тобәкара (регионара) этномәдәни ял лагере эшләде. Этномәдәни лагерьда Мәскәv, Казан шәһәрләреннән, Тvбән Новгород, Ульян, Владимир, Пенза олкәләреннән һәм һәрвакыттагыча Мордовия Республикасыннан торле-торле конкурсларда, предмет олимпиадаларында урыннар яулаган 49 укучы катнашты.      Рус, мордва һәм татар халыкнын телен ойрәнv теләге булдыру, тарихына кызыксыну уяту, халыкларнын милли-мәдәни vзенчәлекләрен саклау, дуслыкны ныгыту, сәламәт яшәv нигезләрен формалаштыру – балалар очен оештырылган «Яшә, туган тел!» дигән этник лагерьнен максаты.

Мондый сменалар балалар тормышында моһим роль уйный, алар туган тел буенча белемнәрен тирәнәйтv генә тvгел, ә актив ял итv, яна дуслар табу һәм vзләрен зур, тату гаиләнен бер олеше итеп хис итv очен уникаль момкинлек бирә. Тагы биредә уеннар, биюләр һәм жырлар аша балалар Мордовия халкынын телен, мәдәниятен тирәнрәк анлыйлар. Балалар белән эшләv лагерьда унай атмосфера тудыру, кызыклы ял оештыру гына тvгел, ә моһим тормыш ориентирларын тапшыру, аларнын жылы һәм шатлыклы истәлекләренен бер олеше булу момкинлеген бирә. Үсеп килvче буынны тәрбияләvгә коч кую - безнен киләчәгебезгә зур олеш кертv дигән сvз, чонки нәкъ менә шушы кызлар-егетләр иртәгәсе кон доньясын тозиячәк.

Мордовия Республикасы Мәгариф министрлыгы балалар очен бай программа әзерләгән: «Тvгәрәк остәлләр», викториналар һәм квестлар, этнодискотекалар,



милли спорт уеннары, «Туган тел» актерлык осталыгы, вокал һәм хореография, декоратив-гамәли сәнгать буенча мастер-класслар vткән. Сменада катнашучылар: Ләмберәнен 1нче урта мәктәбе укучысы Азисова Алина, Ләмберәнен 2нче урта мәктәбеннән Байбиков Радель, Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбе 8 класс укучылары Кулмямятова Айгуль белән Гундина Камила, Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбе 9 класс укучылары Карабанов Салават белән Биккинин Салих, Биккинин Билял

белән Аймуранов Самир (8кл.), Саранск шәһәре 8нче урта мәктәбе 7 класс укучылары Акчурина Диана белән Белохвостикова Виктория. 2008 елдан алып татар группасы белән унышлы Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбенен татар теле һәм әдәбияты укытучысы, “Педагог13.ру” vзәге методисты Фазия Фәрит кызы Боярова эшли.
Балаларнын ялы ничегрәк vтve турындагы әнгәмәдә ул:
- Ике атна дәвамында этносменанын һәр коне торле халыкларнын мәдәниятенә тирәнтен чумарга момкинлек бирә торган кызыклы вакыйгаларга, мастер-классларга, уеннарга һәм экскурсияләргә бай булды. Балалар милли биюләргә ойрәнделәр, халык жырларын жырладылар, кызыклы бәйгеләрдә һәм уеннарда катнаштылар, доньяга карашларын кинәйттеләр һәм милләтара баг-ланышларны ныгыттылар. Лагерь-дагы дуслык, vзара анлашу һәм туган жиргә, vз тамырларына мәхәббәт атмосферасына сенгән иде. Балалар рәхәтләнеп мокшанын «Акша келу», эрзәнен «Раськень Озкс» һәм татарнын «Сабантуй» бәйрәмнәрендә катнаштылар. «Сабантуй» бәйрәмендә кvнелсезлеккә урын юк иде, һәрберсе кvнеленә хуш килгән шогыль тапты, торле милләт балалары рәхәтләнеп коч сынашты: билбау корәше (Биккинин Салих - батыр), кул корәше (Байбиков Радель - батыр), коянтәдә чиләкләрдәге суны тvкми генә ин оста ташучы Белохвостикова Виктория иде, тагын капчыкларда йогерv, мендәрләр белән корәш һәм 

башка эстафеталар да оештырдык. Бәйрәм ярышлары жыр-бию белән vрелеп барды.
Әлбәттә, «Яшә, туган тел!» милләтләр дуслыгы лагерендә ин кызыклы вакыйгаларнын берсе «Россия балалары» ярышында «Дуслык» татар командасы лаеклы I урынны яулау, актерлар мастерлыгында чын дуслыкны кvрсәтеп Берсеневкадан Егор Горин «Дус» биюе белән II урында булуы, «Мистер һәм мисс» конкурсында мистер - Карабанов Салават, вице-мистер - Биккинин Билял, «Халкын мактаган Мордовия татарлары» проектынын жинvчесе шулай ук Карабанов Салават иде.
«Яшә, туган тел!» жәйге тобәкара этномәдәни ял лагерендә торле милләт балалары бер-берсен мәдәниятлары белән баеттылар, дуслаштылар, сәламәтлекләрен ныгыттылар. Әлеге проектта берничә ел беррәттән катнашкан балалар «Сивинь»дә, ойдәге тосле жылылыкны сагынып, Федор Петрович Тултаевка сәламнәрен дә юлладылар, - ди Фазия Фәрит кызы алган тәэсире белән уртаклашканда.

**Наилә НАСЫРОВА**